ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД АГРЫЗ» АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ӘГЕРҖЕ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

05.02.2020 Әгерҗе ш. № 05

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә «Модель норматив-хокукый акт проектын җибәрү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе районы Прокуратурасы мәгълүматы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Әгерҗе муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында http://agryz.tatarstan.ru бастырып чыгарырга..
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының оештыру бүлеге башлыгы Л.Р. Шәриповага йөкләргә.

Җитәкче Ә.М.Рәхмәтулин

Расланган
Татарстан Республикасы Әгерже
муниципаль районының «Әгерже
шәһәре» муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты карары
«05» феврале 2020 № 05

**Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Әгерже шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясау тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының «Әгерже шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен (алга таба - мөрәҗәгать) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының “Әгерже шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау тиешле чорда килгән гражданнар мөрәҗәгатьләрен, шул исәптән язма рәвештә, электрон хәбәрләр рәвешендә, шулай ук гражданнарны шәхси кабул итү барышында һәм телефон аша юлланган гражданнар мөрәҗәгатьләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

3. Гражданнар мөрәҗәгатьләрен анализлау вакыты елына ике тапкыр: яртыеллыкта һәм үткән елда.

4. Һәр яртыеллык йомгаклары буенча җаваплы зат Татарстан Республикасы Әгерже муниципаль районының “Әгерже шәһәре” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына кергән гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ ясаганы өчен гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерә.

5. Анализда түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

- электрон документ рәвешендә мөрәҗәгатьләрне дә кертеп, кергән, үзгәртелгән һәм каралган мөрәҗәгатьләр, шул исәптән телдән һәм язма мөрәҗәгатьләр саны;
- мөрәҗәгатьләрнең структурасын һәм тематикасын;
- шәхси кабул итү өчен җаваплы затларны шәхсән кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны;
- мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый актлар һәм башка актлар (булган очракта).

6. Гражданнар мөрәҗәгатьләренә гомумиләштерелгән анализ Әгерже муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында елына ике тапкыр урнаштырыла http://agryz.tatarstan.ru.